ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 октябрь 2021 ел № 7114

«2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гражданнар оборонасы системасын, халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итүне камилләштерү» муниципаль программасын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гражданнар оборонасы системасын, халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итүне камилләштерү» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләр» 01.13, «Халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгы» 03.10, «Су хуҗалыгы» 04.06 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 2022 елда – 1949,9 мең сум, 2023 елда –1949,9 мең сум, 2024 елда –1949,9 мең сум күләмендә тәэмин итәргә».

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2021 елның 28 октябрендәге
7114 номерлы карарына
кушымта

«2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гражданнар оборонасы системасын, халкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итүне камилләштерү» муниципаль программасы

1 бүлек. Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге гражданнар оборонасы системасын, халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итүне камилләштерү» муниципаль программасы (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге |
| Программаны башкаручылар | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе |
| Программаның максатлары | Яр Чаллы шәһәре халкының, территорияләренең һәм инфраструктура объектларының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән сакланышын күтәрү, аларның тискәре нәтиҗәләрен йомшарту, гражданнар оборонасы өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү |
| Программаның бурычлары | - гражданнар оборонасы, шәһәр халкын һәм территорияләрен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру;<br>- су объектларында һәлак булучы кешеләрнең санын киметү эшен оештыру |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 1 этап – 2022 ел;<br>2 этап – 2023 ел;<br>3 этап – 2024 ел |

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2022 | 2023 | 2024 | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 1949,9 | 1949,9 | 1949,9 | 5849,7 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 1949,9 | 1949,9 | 1949,9 | 5849,7 |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | - шәһәр территориясендә кешеләр үлеме белән табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр булмау;<br>- барлыкка килә торган гадәттән тыш хәлләргә оператив җавап бирү тизлеген арттыру;<br>- гадәттән тыш хәлләрне бетерү, янгыннарны сүндерү, су объектларында кешеләрне эзләү һәм коткару көчләренең һәм чараларының нәтиҗәлелеген арттыру;<br>- халыкны гражданнар оборонасына өйрәтү, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы һәм суда куркынычсызлык чаралары өлкәсендә яхшы нәтиҗәләр тәэмин итү | | | | |
| Программаны тормышка ашыруга контроль оештыру системасы | Программа чараларын башкаручы аларның сыйфатлы һәм үз вакытында үтәлүе, бирелгән финанс средстволарыннан рациональ файдалану өчен җаваплы. | | | | |

2 бүлек. Программаны кабул итү зарурлыгын нигезләү

Программа гражданнарны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм су объектларында кешеләр иминлеге, гражданнар оборонасы бурычларын үтәү, кешеләрне, материаль һәм мәдәни кыйммәтләрне коткару һәм гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән халыкка ярдәм итү дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән. Климатның глобаль үзгәрүе, хуҗалык эшчәнлеге процессында яки эре техноген аварияләр һәм фаҗигаләр нәтиҗәсендә килеп чыккан табигый һәм техноген гадәттән тыш хәлләр Яр Чаллы шәһәре халкы һәм икътисад объектлары өчен шактый куркыныч тудыра.

Әлеге программа гадәттән тыш хәлләр куркынычын киметү өлкәсендә идарә итүне координацияләү механизмнарын үстерүгә, кризис һәм гадәттән тыш хәлләрдә экстрен эш итү системасын оптимизацияләүгә, шулай ук заманча мәгълүмат-коммуникация технологияләрен һәм техник массакүләм мәгълүмат чараларын куллану нигезендә яшәеш иминлеге культурасын формалаштыру алымнарын һәм чараларын булдыруга юнәлдерелгән чараларны үз эченә ала.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә шактый материаль һәм социаль зыян салырлык табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр дә булырга мөмкин.

Куркыныч табигать күренешләре гидрометеорологик күренешләрне (язгы ташулар һәм яңгыр нәтиҗәсендәге ташуларга бәйле су басулар, көчле җилләр, көчле суык, көчле бураннар, боз яву, корылык), куркыныч геологик процессларны – табигый урман янгыннарын үз эченә ала. Барлык саналган бәла-казалардан су басулар, көчле җилләр һәм табигый янгыннар халык һәм территорияләр өчен аеруча зур куркыныч тудыра.

Шәһәр территориясендә янгын куркынычы һәм шартлау куркынычы булган производстволар, энергетика һәм торак-коммуналь хуҗалыгы объектлары булу техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу мөмкинлеге турында белдерә.

Яр Чаллы шәһәре территориясендәге су объектларында кешеләр үлеменең сәбәпләре түбәндәгеләр:

1) кешеләрнең әлеге максатлар өчен җиһазландырылмаган урыннарда су коенуы;

2) алкоголь һәм наркотик матдәләр кулланган килеш су коену яки сулыклар буенда ял итү;

3) балаларның йөзә белмәве;

4) балаларның ата-ана күзәтүеннән башка су коенуы;

5) суда кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрендә билгеләнгән элементар куркынычсызлык нормаларын үтәмәү.

Халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау һәм суда куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә күрсәтелгән проблемаларны хәл итү, өстенлекле чараларны һәм аларны тормышка ашыру эзлеклелеген билгеләп, комплекслы якын килүне һәм моңа барлык дәрәҗәдәге хакимиятне, предприятиеләрне һәм оешмаларны җәлеп итүне, шулай ук халыкта куркынычсыз тәртип культурасын формалаштыру буенча системалы эшләүне таләп итә.

## 3 бүлек. Максатлар һәм бурычлар, индикаторлар

Программаның бурычы булып Яр Чаллы шәһәре халкының, территорияләренең һәм инфраструктура объектларының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән сакланышын күтәрү, аларның тискәре нәтиҗәләрен йомшарту, гражданнар оборонасы өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү тора.

Программаның бурычлары:

- гражданнар оборонасы, шәһәр халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру;
- су объектларында һәлак булучы кешеләрнең санын киметү эшен оештыру.

## Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| Төп чараларның исеме | | Башкаручылар | Төп чараларны башкару сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның зурлыгы | | | | Чыганакны күрсәтеп финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2021 ел (база) | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Максат: Яр Чаллы шәһәре халкының, территорияләренең һәм инфраструктура объектларының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән сакланышын күтәрү, аларның тискәре нәтиҗәләрен йомшарту, гражданнар оборонасы өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | |
| | | | | Кешеләр үлеме белән бәйле табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең саны, берәмлек | 0 | 0 | 0 | 0 | | | |
| Бурыч: гражданнар оборонасы, халыкны һәм шәһәр округы территорияләрен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| 1. | Гражданнар оборонасының иң яхшы саклагыч корылмасына конкурс | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | июнь – сентябрь ел саен | катнашучы оешмалар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |
| 2. | Икътисад объектларының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча иң яхшы укыту-матди базасына смотр-конкурс үткәрү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | июнь ел саен | катнашучы оешмалар саны, берәмлек | 9 | 9 | 9 | 9 | финанслау таләп ителми | | |
| 3. | Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Яр Чаллы шәһәренең төп чаралар планын эшләү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | декабрь ел саен | эшләнгән документ саны | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Шәһәрнең идарә компанияләре карамагында оештырылган гражданнар оборонасы буенча иң яхшы укыту-консультация пунктларына смотр-конкурс үткәрү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | сентябрь ел саен | оешмалар саны, берәмлек | 11 | 11 | 11 | 11 | финанслау таләп ителми | | |
| 5. | Гидротехник корылмаларның эксплуатация ышанычлылыгын күтәрү буенча чара үткәрү | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | ел дәвамында | гидротехник корылмаларны авариясез эксплуатацияләү дәрәҗәсе, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 238,8 | 238,8 | 238.8 |
| 6. | Белем бирү оешмаларының шәхси саклану чаралары белән җиһазланышын контрольдә тоту | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | ел дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 7. | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының шәхси саклану чаралары белән җиһазланышын контрольдә тоту | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | ел дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 8. | Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә бурычларның үтәлешенә хисап елы өчен йомгак ясау | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | ел дәвамында | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | 10,0 | 10,0 | 10,0 |
| Бурыч: су объектларында һәлак булучы кешеләрнең санын киметү эшен оештыру | | | | | | | | | | | |
| 9. | Белем бирү оешмаларында «Судагы куркынычсызлык» темасына сыйныф сәгатьләре үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | уку елы дәвамында | катнашкан балалар саны, берәмлек | 68120 | 68150 | 68155 | 68160 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 10. | Язгы ташу чорында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чаралар планын эшләү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | апрель ел саен | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 11. | Коткаручыларны укытуны оештыру | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | май ел саен | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 12. | Халык күпләп ял итү өчен оештырылган урыннарда җәмәгать коткару постлары булдыру, аларны җиһазландыру һәм эшен оештыру | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе | ел дәвамында | җәмәгать коткару постлары, пляжлар булдыру һәм аларны карап тоту һәм кирәкле җиһазлар белән тәэмин итү | 100 | 100 | 100 | 100 | 1701,1 | 1701,1 | 1701,1 |
| 13. | Пляжларның хуҗалары һәм арендаторлары (судан файдаланучылар) һәм гадәттән тыш хәлләр һәм янгын куркынычсызлыгы буенча комиссия белән «Җәйге чорда су коену һәм халыкның массакүләм ял итү урыннары әзерлеге турында» темасына киңәйтелгән утырыш үткәрүне оештыру | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | май ел саен | чаралар саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| | барлыгы | | | | | | | | 1949,9 | 1949,9 | 1949,9 |

4 бүлек. Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары

Программаны тормышка ашыруның арадаш һәм ахыргы нәтиҗәләрен бәяләү өчен түбәндәге нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары файдаланылачак:

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү | Мәгълүмат чыганагы |
|---|---|---|---|
| 1. | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә килеп чыккан гадәттән тыш хәлләрнең саны | N - сан | ТР буенча Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Баш идарәсе Күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге |

5 бүлек. Программаны тормышка ашыру механизмы һәм сроклары

Программаны тормышка ашыру механизмы программаны тормышка ашыру буенча чаралар эшләү юлы белән шәһәр бюджеты кытлыгы шартларында гамәлгә ашырыла торган проблемаларны хәл итү өчен финанс һәм оештыру-хокукый базаны үз эченә ала. Программа чараларын финанслауның төп чыганагы булып муниципаль бюджет санала.

6 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаның ресурс белән тәэмин ителешен 5849,7 мең сум күләмендә шәһәр бюджеты акчалары тәшкил итә, шул исәптән:

2022 ел – 1949,9 мең сум;

2023 ел –1949,9 мең сум;

2024 ел –1949,9 мең сум.

Программаны тормышка ашыруга ассигнованиеләр кыскарганда яки артканда, программаны башкаручы чаралар исемлегенә төзәтмәләр кертү буенча тәкъдимнәр кертә.

Программаны финанслау күләмнәре прогноз характерына ия һәм билгеләнгән тәртиптә аңа төгәллекләр кертелергә тиеш.

7 бүлек. Программа үтәлешенә контрольне оештыру системасы

Программаны тормышка ашыру белән агымдагы идарә итү аны тормышка ашыру, ахыргы нәтиҗәгә ирешү һәм программаны үтәүгә бүленгән финанс средстволарын нәтиҗәле файдалану өчен җаваплы булган Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлегенең программаны тормышка ашыруның барлык чорында план күрсәткечләренә, финанслау динамикасына һәм үтәлешкә ирешүне бәяләп, программаның үтәлеше турында һәм чираттагы финанс елына планлаштырылган чаралар буенча ел саен бирелә торган доклады хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгына һәм Башкарма комитетның финанс идарәсенә җибәрелә.

Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге, программа чаралары буенча максатчан күрсәткечләргә һәм чыгымнарга, программаны тормышка ашыру механизмына, аны тормышка ашыруга бүленә торган финанс средстволарын исәпкә алып, башкаручылар составына ел саен төгәллек кертә, программа гамәлдә булуның соңгы елында, кирәк булган очракта, аны тормышка ашыру срогын озайту турында тәкъдимнәр (нигезләүләр белән) кертә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева